**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЧӘЛЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 147 "11" апрель 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советы хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 16 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (aznakaevo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан, түбәндәге адреслар буенча:

Үчәлле авылы, Совет ур., 51 йорт (мәдәният Йорты бинасы),

Якты Күл ав., Якты Күл ур., 15 йорт (КФҮ бинасы).

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Рәис Г. М. Төхвәтуллина

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Советының
11.04.2025 елгы 147 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасы


| № п/п | Сайлау округы исеме | Округлар чиге | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Үчәлле № 1 | **Үчәлле авылы**<br>Совет ур. №1 йорттан № 20 йортка<br>Октябрьская ур. | 42 |
| 2 | Үчәлле № 2 | **Үчәлле авылы**<br>Совет ур. №№23,23а йортлар, № 25 алып № 50 йортка кадәр | 42 |
| 3 | Үчәлле № 3 | **Үчәлле авылы**<br>Совет ур.№ 51Б йорттан алып № 83 йортка кадәр | 39 |
| 4 | Үчәлле № 4 | **Үчәлле авылы**<br>Комсомол ур.,<br>Тукай ур. № 1 йорртан алып № 12 йортка кадәр,<br>Совет ур. №№ 21, 22, 24 йортлар | 34 |
| 5 | Үчәлле № 5 | **Үчәлле авылы**<br>Яшләр ур.,<br>Тукай ур.№ 13 йорттан алып № 23 йортка кадәр | 42 |
| 6 | Үчәлле № 6 | **Якты- Күл авылы**<br>Якты- Күл ур. № 1 йорттан алып № 35 йортка кадәр | 35 |
| 7 | Үчәлле № 7 | **Якты- Күл авылы**<br>Якты- Күл ур. № 36 йорттан алып № 47 йортка кадәр,<br>**Текмале авылы**,<br>**Кзыл-Юлдуз пос.** | 33 |


Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 11.04.2025 елгы 147 номерлы карарына 2 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге территориясендә бермандатлы сайлау округлары схемалары

## ГРАФИК СУРӘТЕ

Учаллинское СП М 1:10000




Округ№6
Якты-Куль
ул. Якты-Куль
Стела ВОВ
3D
Округ№7
Текмале
Участникам ВОВ
Кзыл-Юлдуз